# Безнең канатлы дусларыбыз

# 1 станция
# Почта тартмасы



1. Минем башымда кара шапка, аркам һәм канатларым, койрыгым караңгы төстә, ә күкрәгем ачык сары төстә, әйтерсең сары жилет кигән. Җәй көне мин коңгызлар, суалчаннар белән туенам, ә кыш көне нәрсә ашаганымны карамый, бөтенесен рәттән ашап барам: төрле бөртекләр,ипи валчыклары, пешкән яшелчәләр. Бигрәк тә төзланмаган май яратам. Таныдыгызмы мине?



**Песнәк**

Без сезгә ашыгабыз, балалар. Яз җитә. Эшкә тотынырга кирәк: әзер ояларга урнашырга, оя корырга, кошчыклар чыгарырга.



**Сыерчык**

Минем турында нинди генә хикәятләр сөйләмиләр. Хәтта мине кайгы китерүче дип тә саныйлар. Ә чынлыкта мин бик кирәкле кош. Бер төнгә 7 – 8 тычканны юк итәм. Минем бер гаиләм 1 елга 10000 тычканны юк итә, шуның белән 20 тонна икмәкне саклап кала.



**Ябалак**

Күпләр безне яратып бетермиләр, чөнки без чит кош балаларын оядан төртеп төшереп үтерәбез. Ә чынлыкта без бик файдалы кошлар: күп кенә зарарлы личинкаларны ашыйбыз, хәтта аларның кайберләрен башка бернинди кош та ашамый.



**Күке**

Ә без язның
беренче
хәбәрчеләре…



**Кара каргалар**

Мине «урман каравылчысы» дип атыйлар. Мин агачта, агач куышында яшим. Гомерем буе аяк өстендә, анда- монда йөгерәм, агач буенча астан - өскә, өстән – аска, ә миңа канатлар бер агачтан икенче агачка күчәр өчен генә кирәк.



**Үрмәләч**

# 2 станция
# Кошлар тавышы





# Бак – бак - бак



Үрдәкләр

# Каркылдыйлар



Каргалар

# Ка – Ка - Ка



казлар



# хылдыйлар

ябалакла
р

# Чыелдыйлар



Песнәклә
р

# Сызгыралар



сандугачл
ар

# 3 станция
# Кошлар профессияләре





# Кош – балта остасы



Тукраннар – сәгатьләр буе агачта тукылдыйлар, аннан шул вакытта аннан бик күп бөҗәкләрне өстерәп чыгаралар.

# Урман мәчесе



Шәүләгән куркыныч килгәндә мәче кебек кычкыра. Ә яшен алдыннан шәүләгән биек агачның иң очына менеп утыра, бу вакытта ул флейтада уйнаучы музыкант тавышын чыгара.

# Төзүче кош



Иң оста оя коручылар булып карлыгачлар санала

# Акробат кош



Үрмәләч агач
бунча баштүбән
үрмәли.

# Төнге ерткыч



Ябалаклар ауга
төнлә чыгалар
һәм
тычканнарны
бөтен килеш
кабып йоталар.

# Башлап җырлаучы



Сандугач. Аның турында: «Урман оркестрында беренче скрипка – иң нечкә кыллы, иң яңгыравык» - диләр.







# Кошларның дусларына хас кагыйдәләр.

- *1.Кош ояларын туздырмаска.*
- *2.Кошларга рогаткадан атмаска.*
- *3.Кошларга оялар һәм җимлекләр ясарга.*
- *4.Кыш көне кошларга азык куярга*



Кыш көне кошларның тереклеге турыдан – туры кешеләр белән бәйле. Бигрәк тә кошларга көчле салкыннарда һәм кар – буранда азык табуы кыен. Шулай ук кошларга агачларның ботаклары боз белән каплпнга кыенга туры килә, бу вакытта алар качкан бөҗәкләр һәм агачны бөреләренә килеп җитә алмаска мөмкин. Салкын көннәрдә кошлар 6 сәг. ач торсалар үләргә мөмкин. Шуңа күрә аларны өстәмә ашатырга кирәк була. Поэтому и возникает необходимость подкормки Ә җимлекләр янында нинди кошларны күрергә мөмкин соң?





КҮК КҮГӘРЧЕН Кеше тирәсендә иң еш очрый торган кошларның берсе. Утрак кош. Кеше тирәсендә азык калдыклары, кузаклы, бөртекле культуралар, чүп үләннәре орлыклары белән туена. Күбесенчә җирдә туена, агачларга сирәк утыра. Зур торак пунктлар тирәсендә зур өерләр хасил итеп тереклек итәләр.



ЧЫПЧЫКЛАР. Күбрәк җирдә туеналар, сирәк кенә куак һәм агачларда. Җирдә сикереп – сикереп йөриләр. Көз көне алар зур өерләр хасил итеп, кеше торакларына якын ук киләләр. Туклануларында төрле үсемлек орлыклары өстенлек итә, шулай ук икмәк калдыклары.

# КОШЛАРНЫ САКЛАГЫЗ!

Карлыгачны җәберләмә
Ул ераклардан очып килә
Безнең якта бала үстерә
Аның оясын син җимермә!
Кошларның син дусты бул!
Синең тәрәзәң төбендә
Яз көне җырласын сандугач,
Җир киңлекләрендә һәрвакыт
Очсын көтүе белән күгәрчен!

Муса Джангазиев

